**Комитет по стандарту «Халяль»**
**Централизованной религиозной**
**организации – Духовного управления**
**мусульман Республики Татарстан**

**“Halal” Standardization Committee**
**Central religious organization - Muslim**
**Religious Board of Tatarstan Republic**

**«Хәләл» комитет оешмасы**
**Үзәкләшкән дини оешма Татарстан**
**Җөмһүрияте мөселманнарының**
**диния нәзарәте**

**الادارة الدينية لمسلمي جمهورية تتارستان**
**الجنة الحلال**

**«08» сентябрь 2016 ел**

**Әссәләмү гәләйкүм үә рахмәтүЛлаhи үә бәрәкәтүhү!**

Татарстан республикасы мөселманнарының Диния Нәзарәте каршысындагы «Хәләл» стандарт Комитеты исеменнән Сезне чын күңелдән Мобарәк Корбан гаете белән тәбрик итәм!

Корбан гаете барлык мөселманнарны берләштерә, якынайта, аларның күңелләре сөю-хөрмәт вә бер-берсенә карата миhербанлык hәм шәфкатьлелек хисләре белән тула. Бу мөбарәк көнне нәфрәт-ачулар юкка чыга. Дошманлык hәм үпкә хисләре бетә. Кешеләр корбанны Аллаhы Тәгалә ризалыгы өчен чалып, гаиләсен, килгән кунакларын hәм күршеләрен, фәкыйрьләрне вә мескеннәрне хөрмәт итеп, аларның күңелләрен күрәләр.

Ошбу мобарәк бәйрәм көннәрендә, Аллаhы Тәгалә барчабызга да ихлас күңелдән бары тик файдалы, изге гамәлләр кылырга насыйп итсен! Күңелләребездә булган барлык изге ниятләребезгә, максатларыбызга ирештерсен! Бөек Раббыбыз, ихласлылык белән чалган корбаннарыбызны, кылган барча изге гамәлләребезне кабул итеп, ике дөнья бәхет-сәгадәтенә ирештерсен! Йортларыбызга нур иңсен, табыннарыбыз мул булып, hәрвакыт хәләл ризык белән тулып торсын!

**Иң изге теләкләр белән,**
**Комитет рәисе** **М.Р. Низамов**

420021, Россия, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Габдуллы Тукая, д. 3. Тел. +7 (843) 292-20-08, тел./факс: 238-33-71
Web-site: www.halalrt.com E-mail: info@halalrt.com